КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ПО ОХРАНЕ ОБЪЕКТОВ
КУЛЬТУРНОГО НАСЛЕДИЯ

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ МӘДӘНИ
МИРАС ОБЪЕКТЛАРЫН
САКЛАУ КОМИТЕТЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

18.02.2025 № 70-П

Җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектларының тарихи-мәдәни әһәмияте категориясен региональ әһәмияттәге мәдәни мирас объектларының тарихи-мәдәни әһәмияте категориясенә үзгәртү турында

2002 нче елның 25 нче июнендәге 73-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкарьләр) турында»гы Федераль законның 22 нче статьясындагы 3 нче пункты, дәүләт тарихи-мәдәни экспертизасының 2025 нче елның 17 нче гыйнварындагы уңай бәяләмәсе нигезендә боерам:

1. Әлеге боерыкка караган 1 нче кушымта нигезендә, җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектларының тарихи-мәдәни әһәмияте категориясен региональ әһәмияттәге мәдәни мирас объектларының тарихи-мәдәни әһәмияте категориясенә үзгәртергә.

2. Боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Рәис И.Н. Гущин

Татарстан Республикасы
Мәдәни мирас
объектларын саклау
комитетының 2025 елның
18 нче февралендәге 70-П
номерлы боерыгына
караган 1 нче кушымта

**Тарихи-мәдәни әһәмияте категориясе региональ әһәмияттәге мәдәни мирас объектларының тарихи-мәдәни әһәмияте категориясенә үзгәртелгән җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектлары**

| № | Мәдәни мирас объектының исеме, төзелү даталары, төре | Мәдәни мирас объекты урнашкан урын |
|---|---|---|
| 1 | «Богородица хатын-кызлар монастыре», XVII гасыр ахыры-XIX гасырның икенче яртысы (объект төре-ансамбль) | Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Зур Кызыл урам, Япеев урамы. |
| 2 | «Мәгарәле храмы булган Казан Мәрьям Ана иконасы соборы хәрабәләре. XVI гасыр ахыры – XIX гасыр башы, 1910 - 1913 еллар», XVI гасыр ахыры – XIX гасыр башы, 1910 – 1913 еллар (объект төре-һәйкәл) | Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Зур Кызыл урам, 5 нче б йорт |
| 3 | «Никола Тульский чиркәве», 1806 - 1816 еллар (объект төре – һәйкәл) | Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Зур Кызыл урам, 3 нче йорт |
| 4 | «Крестовоздвиженский чиркәве», 1865 - 1877 еллар (объект төре – һәйкәл) | Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Зур Кызыл урам, 5 нче йорт, литеры 4 |
| 5 | «Настоятель корпусы бинасы», 1810 - 1832 еллар (объектның төре – һәйкәл) | Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Япеев урамы, 11/2 нче йорт, литеры 1 |
| 6 | «Монастырь кунакханәсе бинасы», 1838 ел (объектның төре-һәйкәл) | Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Зур Кызыл урам, 5 нче а йорт |
| 7 | «Монахинялар өчен корпус бинасы», 1814 ел, 1842 ел (объект төре – һәйкәл) | Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Япеев урамы, 11/1 нче йорт, литеры 1 |
| 8 | «Чиркәү-мәхәллә мәктәбе бинасы», 1895 ел (объек төре-һәйкәл) | Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Япеев урамы, 9 нчы йорт |
| 9 | «Манаралы койма һәм керү капкалары», 1830 - еллар (объект төре - һәйкәл) | Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Япеев урамы, 11/2 йорт, литерлары 2, 3 |